**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** КАРАР

16 сентябрь 2022 ел **Чирмешән авылы** № 319

«Торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 февралендәге 75 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 февралендәге 75 номерлы карары белән расланган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.6.1 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 10 пунктчаны бәян итәргә: «10) социаль түләүләр алу турында мәгълүматлар - Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды»;
- 15 пунктчаны бәян итәргә: «15) индивидуаль лицевой счетның иминият номеры (СНИЛС) турында мәгълүматлар - Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды»;
- 18 пунктчасын бәян итәргә: «18) фамилияле-исемле төркем, туган көн, җенес һәм СНИЛС туры килүен тикшерү - Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга (pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Т.Айбатов